РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

улица К.Маркса, дом 46,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

К.Маркс урамы, 46 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел.(84342) 5-13-38, тел/факс 5-13-38, E-mail: chistay@tatar.ru

***Постановлени***
***29.03.2023*** ***г.Чистополь*** ***Карар***
***№40***

Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары милкендә булган яки ялгыз яшәүче гражданның 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәтенең бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 91.3 статьясы нигезендә «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы 2015 елның 16 мартындагы 13-ЗРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Һәр гаилә әгъзасына, яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле керемнең максималь күләмен билгеләү Методикасы белән, шулай ук «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыгының 2023 елның 31 гыйнварындагы 18 номерлы хатына нигезләнеп, Чистай шәһәре Башкарма комитетына

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарны торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен гражданнар кеременең максималь күләмен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары милкендәге һәм һәр гаилә әгъзасына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме - 738 630 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме - 21 464 сум.

2. Чистай шәһәр Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенең баш белгеченә гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Чистай шәһәр Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенең баш белгеченә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ф.Рәхимов